| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ШАРЛИАРЕМИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ № 5 КАРАР

3 ноябрь 2022 ел

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, 18.1 статьясы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Уставы нигезендә:

1.Сөлек авылы клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 18 ноябренә 13 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан һәм армия сафларында хезмәт итучеләрдән тыш, 2023 елда үзара салым акчаларын кертүгә, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

- Сөлек авылында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
-МТЗ-320,4 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт өчен түләү);
- бәйрәмнәрне үткәрү өчен бүләкләр (Сабантуй, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, 9 Май);
- Сөлек зиратын эйләндереп алу очен профнастил сатып алу;
- Сөлек авылында биек агачларны кису;
-Сөлек авылында урам утларын карап тору(лампочкалар сатып алу).

«ӘЙЕ»ЮК".

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» PRAVO.TATARSTAN.RU («Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында) һәм «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация

челтәрендә, Сөлек авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы
Сарман муниципаль районы башлыгы Н.Н.Хуҗина